КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 март г.Казань № 291

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карары белән расланган Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карары белән расланган Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Сайлап алуны үткәрү максатларында, Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minstroy.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт), түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын һәм электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 3.4 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

сатып алына торган махсус һәм коммуналь техника, машиналар һәм җиһаз санын һәм төрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итеалә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

предприятиеләргә карата таләпләрне һәм буТәртипнең 2.3 һәм 2.4 пунктлары нигезендә документларның күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртип нигезендә предприятиеләр заявкаларын карап тикшерү кагый-дәләрен;

предприятиеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану вакытын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене Килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый торган рәсми сайтта урнаштыру датасын.

Сайлап алуны үткәрү чорында сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, Министрлык тарафыннан предприятиеләргә Министрлыкка тиешле сорату кергән датадан биш эш көне эчендә электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.»;

3.2 пунктның дүртенче абзацында «нәтиҗәгә ирешү турында хисап бирү» сүзләрен «субсидия алучы тарафыннан нәтиҗә күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирү» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия алучы Министрлыкка квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5еннән дә соңга калмыйча, Килешүнең Татарстан Республикасы

Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирә.»;

V бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Контрольдә тотуны (мониторингны) гамәлгә ашыруга карата таләпләр»;

5.1 пунктта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $5.1^1$ пункт өстәргә:

«$5.1^1$. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгалләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

5.3 пунктның икенче абзацында татар текстында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе күрсәткеченә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме алтынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин